| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СРЕДНЕКУШКЕТСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>УРТА КӨШКӘТ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» январь 2022 ел № 2

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында " 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары», Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында " 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары» белән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 1 февраленнән Балтач муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 6964,88 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2020 елның 30 гыйнварындагы 3 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы: Перфилов Ю.М.

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Урта Көшкәт авыл җирлеге
Башкарма комитетының
«28» гыйнварь 2022 ел, № 2 карарына

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең бәясенең гарантияле исемлеге

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (бер сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләр бирү һәм китерү | 3064,83 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 864,43 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 3035,42 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Кушымта № 2
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Урта Көшкәт авыл җирлеге
Башкарма комитетының
«28» гыйнварь 2022 ел, № 2 карарына

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең бәясенең гарантияле исемлеге

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (бер сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тәнне юу | 263,95 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләр бирү һәм китерү | 2800,88 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 864,43 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 3035,42 |
| Барлыгы | 6964,68 |